5нче сыйныфта тәрбия сәгате.

Тема: Һөнәр сайлау – язмыш сайлау.
Максат: Укучыларга кеше тормышында һөнәрнең бик мөһим урын тотуына төшендерү.
Укучыларга тиешле белгечлек сайлап алу юнәлеше бирү.
Һөнәр сайлауда җаваплылык хисе, җитди булу сыйфаты формалаштыру, гаилә тарихын өйрәнүгә этәргеч булдыру, һәртөрле хезмәткә, хезмәт кешесенә хөрмәт хисләре тәрбияләү.
Җиһаз : комп.
Һөнәр сайлау принциплары язылган плакат, профиль сайлау картасы.
"Һөнәр сайлаганда" дигән китаплар күргәзмәсе.
Уку йортларының укырга кабул итү шартлары язылган белдерүләр. Нинди имтихан бирәләр?
Дәрес барышы.
1. Кереш өлеш.

Укучылар, бүген һөнәрләр һәм профиль сайлау турында сөйләшербез. Һөнәр сайлау – кеше тормышында иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе. Заман үзгәрә барган саен, тормыш яңа һөнәрләр таләп итә. Гомерлек юлны сайлау бик авыр. Бу хакта яшьтән үк уйлана башларга кирәк. Тора-бара яңа теләк-хыяллар барлыкка килергә мөмкин. Ә инде югары сыйныфларда укыганда үзеңә кирәкле профиль буенча белемнәрне арттыра алу мөмкинлеге булганда 9 нчы класста дөрес профиль сайлау – иң мөһим мәсьәлә.

**I.** Уку мәсьәләсен кую.

Күренекле мәгърифәтче, галим Каюм Насыйри үзенең " Тәрбия китабы"нда балаларга биргән нәсыйхәте белән танышыйк. ( слайд) "Әй җаннарым, угланнарым, хикәятемне ишетегез – һөнәр өйрәнегез. Дөньяның байлыгына ышанырга ярамый. Алтын-көмешләр кеше өчен хәтәрдер: аны я карак алып китә, я утта янып бетә. Әмма һөнәр ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе байлыгын югалтса да кайгырмас. Әй угыл, син дә шулай һөнәр өйрән, тәрбияле бул, белем ал"

Бу хикәяттән ниләр белеп калдыгыз? Нигә К. Насыйри аны беренче хикәят итеп алды икән? Һөнәргә өйрәнергә куша. Тәрбияле дә, белемле дә булыгыз, ди. Һөнәрле кеше – бай кеше. Малы югалса да, ул үзе югалмый. К. Насыйри да иң беренче баланы кечкенәдән һөнәргә өйрәтергә кирәклеген әйтә.

-Әйе укучылар, һөнәре булган кеше үз белгәннәрен башкаларга да өйрәтә

Һөнәрнең кеше тормышында мөһим урын тотуы турында фикер алышырбыз.

III. Уку мәсьәләсе чишү.

1нче бирем.

-Нәрсә ул һөнәр? Лексик мәгънәсен ачыклыйк

Кул көче белән башкарылган эш.

Нинди һөнәрләр турында ишетеп, күреп, укып беләсез?

Балта остасы, тимерче, сәгать төзәтүче, аш пешерүче, элемтәче.

2 нче бирем.

- Нинди дә булса һөнәргә ия булу өчен нәрсәләр эшләргә кирәк, кайсы сыйфатларны үзеңдә булдырырга кирәк? *( Укырга, түземлек, сабырлык, ихтыяр көче, тырышлык, теләк, сәләт)*

- Нәрсә ул профессия?

- Билгеле бер хәзерлек, белем таләп итә торган хезмәт.

- Һөнәр белән профессия арасында аерма бармы?

- Бар. Профессия алу өчен махсус уку мәҗбүри, ә һөнәрнең кайберләрен укымыйча да үзләштереп була.

Һөнәр- 1.Кул көче белән нинди дә булса эшләнмәләр ясау, җитештерү очен махсус күнекмәләр таләп ителә торган эш, кәсеп. Нинди дә булса олкәгә караган белгечлек, профессия, шогыль.

2.Үзенә хас алым , методлар системасы булган берәр төрле практик эшчәнлек өлкәсе. Һәвәскәрлек, нинди дә булса эшкә осталык, мавыгулык.

(Татар теленең аңлатмалы сүзлеге)

- Үзегезнең танышларыгыз, дусларыгыз, туганнарыгыз арасыннан нинди Һөнәр осталарын әйтә аласыз? (җаваплар)

- Сезгә кызыклы сорау бирәсем килә. Укымыйча яки эшләмичә яшәп буламы? *( Кешенең һөнәре, кәсебе, шөгыле булырга тиеш. Юк, бу очракта кеше начар юлга баса.)*

- Сезгә бигрәк тә һөнәрле булу кирәк. Сез барыгыз да егетләр - булачак гаилә башлыклары. Шулай булгач, сез яклаучы, саклаучы, туендыручы кеше булачаксыз. <u>(    нче слайд)</u>

- “Хезмәт – дөньяда бары тик кешегә генә хас һәм ул гына лаек булган бәхет ул “ дигән сүзләр белән килешмичә мөмкин түгел. ( К.Ушинский )

Гадәттә, малайлар әтиләренә охшарга тырыша. Әтиегез яки әниегез белән уртак шөгылегез, алардан өйрәнгән һөнәр турында сөйләгез. Сезне кызыксындырган һөнәр нинди?

- Безнең укучылар һөнәр сайлау турында уйланалармы ? Аларның фикерләрен белү максатыннан, түбәндәге анкета сораулары бирелгән иде. ( нче слайд). Нәтиҗәләр белән танышыйк.

- 1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
- 2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
- 3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
- 4.Кайсы мөһимрәк:
- а) кызыклы эшме;
- ә) зур акчамы;
- б) югары дәрәҗәме?
- 5. Югары белем алырга телисеңме?
- 6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
- а) армиягә бармас өчен;
- ә) күп акча эшләү;
- б) яхшы укыйм;
- в) әти -әни теле.

Анкета нәтиҗәләренән күренгәнчә һөнәр сайлау теләкләрегез зурдан икәне күренә.

1.Сорауга җаваплар төрле: тәрҗемәче, эретеп ябыштыручы, тәрбияче, инженер, юрист, программист,укытучы

2. Кызыклы, һәрвакыт кирәк, балалар яратам, әтием шул һөнәр иясе, ошый кебек җаваплар

3.Кызыклы эш-2, зур акча-3, югары дәрәҗә-2

4.Әйе-7

5. Әти-әни теле- 2, күп акча эшләү- 4, яхшы укыйм-1

Нәтиҗә. Үзегез эшли алырдай сәләтегез булган гына һөнәр сайлагыз.

ТНВ да “Һөнәр” тапшыруы бара, шуны карарга тәкъдим итәм.

Мәкальләрне дәвам ит!

1. Һөнәр иясе бай булмас, бай булмаса да ач булмас.

2. Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау бәхетне төшендә күрер
3. Һөнәр утта янмый, суда батмый торган хәзинә
4. Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.
5. Һөнәрленең кулы алтын, акыллының акылы алтын.
6. Һөнәрле үлмәс,..................һөнәрсез көн күрмәс.
7. Хезмәт иясе-.................хөрмәт иясе.
8. Эше барның...............ашы бар.
9. Эш сөйгәнне..................ил сөйгән.
10. Агачны яфрак бизәсә,...................кешене хезмәт бизи.

Игътибарлылыкка уен.

1 төркем.

1. Күзе яхшы күрә, сәламәт, акыллы, түзем, тиз фикерли, компьютерны яхшы белә (программист)
2. Аралашучан, батыр, сабыр, күп укучы, матур сөйләшүче, күп йөрүче, табигатьнең бөтен авырлыгына түзә алучы (почтальон)
3. Таза, сәламәт, акыллы, батыр, биектән курыкмаучы кеше (очучы)
4. Иҗади, хыялый, күп күрә белүче, тырыш, сабыр, төсләрне аеручы, табигатьне һәм кешеләрне яратучы, эш коралы – пумала (рәссам).

2 төркем.

1. Хезмәт ярата, игътибарлы, сабыр, төсләрне аеручы, юл билгеләрен яхшы белә, кешеләр белән тиз уртак тел таба (шофер)
2. Үсемлекләр үстерү өчен җанын-тәнен кызганмаучы хезмәт иясе, җәй көне басудан кайтмый (агроном).
3. Сызымны яхшы сыза, укый, планлаштыра, оста сөйли, ышандыра, үзен яклый, эшен күрсәтә, төрле проектлар эшли. (архитектор)
4. Матур яза, балаларны ярата, әдәпле, күп белән, сабыр, таләпчән (укытучы, педагог)

<u>Укытучы:</u> Соңгы еллардагы статистик мәглүматълар буенча 40 000 төр һөнәр булуы билгеле. Һөнәр сайлаганда хезмәт базарындагы хәлләрне дә истә тоту зарур.

Хезмәт базарындагы яңалыклар

1.Чыгыш. Бүген Татарстан республикасында югары белем алырга теләүче яшьләрнең саны артык күп. Ә республика икътисады югары белемле белгечләргә түгел, нәкъ менә эшче кулларга 4 мәртәбә кытлык кичерә. Предприятияләрдә белгечләр генә түгел, эшче куллар да җитешми. Бүгенге көндә аларда теләсә кем эшли дә алмый. Иң беренче чиратта компьютерны бик яхшы белү таләп ителә. Бүгенге көндә Татарстанда һөнәри белем бирүнең сыйфатын күтәрү программалары тормышка ашырыла. Кайда белем алуың мөһим түгел иде. Хәзер, киресенчә, һөнәри хәзерлек алга чыкты.

2.”Һәркемнең үз фикере” уены.

- Хәзер без уен уйнап алырбыз. Сезнең һәрберегезгә дә кәгазь битләре бирелгән, шуларны алыгыз. Күзләрегезне йомыгыз, кәгазь битен урталай бөкләгез һәм бер кисәген ертып алыгыз... ә хәзер күзләрегезне ачыгыз. Кәгазь битләрен җәегез һәм өскә күтәрегез. Биттәге бизәкләр бер-берсенә охшаганмы? (Җаваплар тыңлана)

- Бу уеннан нинди нәтиҗә ясыйбыз? (Җаваплар тыңлана)

- Әйе, һәркемнең дә үз фикере бар. Сез шәхси фикерләрегезне бүгенге тәрбия сәгатендә белдерерсез дип ышанабыз.

3. Әңгәмә.

Һөнәр сайлаганда без иң элек нәрсә турында уйлыйбыз? (фикерләре тыңлана).

Әйе, барыннан да бигрәк, теге яки бу һөнәр безгә ошыймы? Безнең өчен кызыклымы ул? Без бу эшне башкарырга сәләтлеме? Аннан соң хезмәт базарында эшләр ничек торуы турында уйлыйбыз: бәлки безне кызыксындырган һөнәр җәмгыятькә кирәк түгелдер? Бу очракта эш таба алмавыбыз да ихтимал. Безнең карарыбызда әти-әниебез, дуслар киңәше, массакүләм мәгълүмат чаралары да йогынты ясарга мөмкин.

Профиль сайлауның 5 принцибы.

Һөнәр сайлау җиңел түгел. Аны сайлауның да үз принциплары бар. Хәзер шулар белән танышып китик. (Плакат эленә).

1. Балаларның шәхси кызыксынулары.
2. Гаилә традицияләре.
3. Баланың укудагы уңышлары.
4. Җәмгыять тарафыннан таләп ителүе укырга керү өчен мөмкинлекләр булуы

5.<u>Һөнәрләр төркеме.</u>

- Кеше – кеше.( тәрбияче, сатучы, ...)
- Кеше – табигать ( агроном, зоотехник, ...)
- Кеше – техника ( токарь, слесарь, ...)
- Кеше – билгеләр системасы ( хисапчы, кассир, ...)
- Кеше – сәнгать образы ( рәссам, буяучы, ...)
- Профессия сайлау картасы.

Хәзер җәмгыять үсеше күп төрле белгечлекләр тәкъдим итә.

Сезгә һөнәрләр язылган таблица бирелгән. Шуңа карап үзегезгә охшаган һөнәрне билгеләгез. Әлеге әти-әниләрегез, укытучылар да сезгә нинди һөнәр сайларга кирәклеге турында фикерләрен белдерерләр. Үзегез сайлаган һөнәрне, уку йортына керү мөмкинлеген билгеләгез.

Бу тест киләчәктә нинди һөнәр иясе булуыгыз һәм сезнең хыялларны билгеләячәк.

Үзегез турында күбрәк белер өчен геометрик фигуралар белән эшләнгән шаян тест ярдәм итәр. 3 геометрик фигура- өчпочмак, түгәрәк, квадрат кулланып 10 элемнттан торган кеше рәсеме ясарга. Бөтен фигураларны кулланырга. Эшнең сыйфаты әһәмиятле түгел. Артык өлешләр ясалса, аларны сызып куярга, ә җитмәсә өстәп ясарга. 30 секунд вакыт бирелә. *(Укучылар ясый).)*

Тестның нәтиҗәсен ачыклау өчен өчпочмакларны санагыз

*Беренче тип:* 6-8 өчпочмак. Җитәкчеләр тибы, яхшы укытучылар. Лидерлык сыйфаты бик ачык сизелә, кешеләрне бик яхшы аералар, мәгълүмат белән эш итәләр.

*Икенче тип:* 5 өчпочмак. Җаваплы башкаручы, яхшы оештыру сәләтле. Үзенең эшчәнлеген азагына кадәр уйлап эш итүче яхшы белгеч.

*Өченче тип:* 4 өчпочмак. Талант һәм кызыксыну төрлелеге бар. Шәхси эшкә сәләтле.

*Дүртенче тип:* 3 өчпочмак.  Галим тибы. Бер эш төреннән икенчесенә җиңел күчә ала.

*Бишенче тип:* 2 өчпочмак . Сәнгать белән ,  кеше белән кызыксыну көчле. . Яңа, гадәти булмаганны бик тиз сизүчән.

*Алтынчы тип:* 1 өчпочмак. Уйлап табучы, рәссам, конструктор. Күзаллау  сәләте көчле.

Бу тест  сезнең төрле яклап талантыгызны күрсәтми. Ә шулай да ул үзегез, мөмкинлекләрегез, сәләтегез турында уйланырга мәҗбүр итәр. Бу сәләтегезне үстерә башларга ,  һөнәр сайларга ярдәм итәр.

IV. Нәтиҗә ясау, йомгаклау.

Укытучы: -  Һөнәрләр бик күп. Кайсын гына алсак та, аларның һәрберсе җәмгыятебез өчен бик кирәкле. Һөнәре булган, кулыннан эш килгән кешенең җирдә һәрвакыт үз урыны, үз юлы, үз һөнәр җимешләре була. Нинди генә чорда яшәсәк тә, без намуслы хезмәт кешеләре булып көн итәргә тиешбез. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигән мәкаль һөнәр белгән һәр кешегә туры килә. Һөнәрегез булса, авырлыктан курыкмасагыз, эш яратсагыз, сез үзегезне иң бәхетле кеше дип саный аласыз.

Шуны онытмагыз: һөнәр сайлаганда сез үз язмышыгызны сайлыйсыз. Сайлаган һөнәрегез үзегезгә ошый һәм шатлык китерә торган булсын.

Һөнәрләр күп: кем булсаң да
Игенчеме, эшчеме?
Тик онытма бер нәрсәне:
Хезмәт бизи кешене.

Яраткан хезмәтең булу – зур бәхет. Бу бәхет сезне читләтеп үтмәсен, илгә-көнгә яраклы, туганнарыгызга, якыннарыгызга, гаиләгезгә кирәкле булып яшәгез дигән теләктә калам.

Кадерле укучылар! Бүгенге тәрбия сәгатенең төп максаты – һөнәр сайлау иде. Алга таба сайлаган юнәлешегез буенча белемегезне тирәнәйтегез һәм алдыгызга куйган максатка ирешегез!

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:

а) кызыклы эшме;
ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни тели.

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:
а) кызыклы эшме;
ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни тели

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:
а) кызыклы эшме;

ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни теле.

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:
а) кызыклы эшме;
ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни теле.

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?

2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:
а) кызыклы эшме;
ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни тели.

1. Киләчәккә нинди һөнәр сайлар идең?
2. Ни өчен бу һөнәрне сайладың?
3. Әти-әниең фикере белән туры киләме?
4.Кайсы мөһимрәк:
а) кызыклы эшме;
ә) зур акчамы;
б) югары дәрәҗәме?
5. Югары белем алырга телисеңме?
6. Ни өчен югары белем алырга телисең?
а) армиягә бармас өчен;
ә) күп акча эшләү;
б) яхшы укыйм;
в) әти -әни тели.

# ҺӨНӘР САЙЛАУ